# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ПРОЗАСЫ ӘСӘРЛӘРЕН АНАЛИЗЛАУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

# ӘСӘР АНАЛИЗЛАУГА КУЕЛГАН БУРЫЧЛАР

-укучыларның танып-белү һәм текст белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен активлаштыру;

-әдәбият теориясеннән һәм әдәбият тарихыннан булган белем һәм күнекмәләрне үстерү;

-әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен, темасын, тормыш материалларын һ.б. танып-белү күнекмәләре формалаштыру, сәнгатьчә эшләнештән иң әһәмиятле үзенчәлекләрне билгеләү;

-укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерүдә, күргән-белгәннәр һәм укыган-өйрәнгәннәр турында логик эзлекле итеп язма һәм телдән белдерергә өйрәтү, матур әдәбиятны сүз сәнгате буларак танып-белү.

# ӘДӘБИ ӘСӘРГӘ ГОМУМИ АНАЛИЗ БУЕНЧА КИҢӘШЛӘР

(Д.ЗАҺИДУЛЛИНА БУЕНЧА)

1. Әсәрне иҗат иткән язучының кайсы чорда, нинди шартларда яшәгән һәм иҗат иткәнлеген исәпкә ал. Язучы иҗат иткән тарихи шартларны билгеләгәндә генә, әсәрдәге вакыйгаларга, андагы образларга, тел, стиль һәм милли үзенчәлекләргә дөрес бәя бирергә мөмкин. Монда ук әсәрнең кайсы елда язылуын күрсәт.
2. Әсәрнең нинди жанрда язылуын һәм бу жанрның үзенчәлекләрен ачыкла. Һәр жанрның үзенең анализ элементлары, аермалыклары барын да истә тот.
3. Әсәрне дөрес итеп, игътибар белән укып чык. Кычкырып уку, эчтән уку, кеше укыганны күзәтеп бару, сайлап уку, йөгерек уку һ.б. форманы сайлый аласың.
4. Эчтәлекне сөйләп чык (тулысынча, өлешчә яки сорауларга җавап рәвешендә).
5. Әсәрне өлешләргә бүл (вакыйгаларның үзгәрүеннән, образларның гамәлләреннән, язучының фикерләре үзгәрүеннән чыгып, әсәрне өлешләргә бүлү – анализның мөһим элементы).
6. Әсәрнең төзелешен, композициясен күз алдына китер. Сюжетын билгелә: төенләнешен, вакыйгалар үстерелешен, кульминацион ноктасын, чишелешен ачыкла.

7. Әсәрнең темасын билгелә. Гадәттә тема анализның башында ук ачыклана. Әсәрнең нәрсә турында булуы, нинди хәлләрне ачыклавы, нәрсәгә багышлануыннан чыгып, аның темасы билгеләнә.
8. Әсәрдәге образларны, геройларны билгелә, аларны төркемлә, төп һәм ярдәмче образларга бүл. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен, каршылыкларын, эшләрен күрсәт. Образларны сөйләмнәренә, тышкы кыяфәтенә, тышкы һәм эчке дөньяларына, характерларына бәя бир. Геройлар яшәгән, формалашкан мохиткә игътибар ит.
9. Әсәрдә булган сурәтләүләргә: чагыштыру, каршы кую, тасвирлау, әсәр телендәге образлы сүзләр, фольклор элементларына игътибар ит һәм аларның әһәмиятен ач.
10. Әсәрнең эчтәлеген үзләштергәннән соң, язучының төп фикерен - әсәрнең идеясен билгелә.
11. Әсәрне бербөтен итеп күз алдына китер, ягъни синтезла.
12. Әсәрнең милли үзенчәлеген, аның халыкчанлыгын, татар һәм дөнья әдәбиятында тоткан урынын билгелә.
13. Әсәр турында үзеңнең фикереңне әйт: ул нинди тәэсир калдырды?

# ЧӘЧМӘ (ЭПИК) ӘСӘРГӘ АНАЛИЗ ТӘРТИБЕ

1. Әсәр кайсы елда языла?
2. Әсәр язылган чорда илдә барган вакыйгалар.
3. Язучының иҗади югарылыгы (нинди әсәрләр язган, иҗат методы, нинди гаиләдә тәрбияләнгән, иң күренекле әсәре).
4. Әсәрнең жанры (роман, повесть, хикәя, новелла һ.б.) Ни өчен роман яки башка жанрга керүен дәлиллибез
5. Темасы (әсәр нәрсә турында?).
6. Идеясе (автор нәрсә әйтергә теләгән?).
7. Проблемалар.
8. Сюжет элементлары (пролог – экспозиция – төенләнеш – вакыйгалар үстерелеше – кулминация – чишелеш – эпилог).
9. Образлар системасы (төп һәм ярдәмче, актив һәм пассив, уңай һәм тискәре).
10. Портрет.
11. Интерьер.
12. Табигать күренешләре.
13. Әсәр кем исеменнән сөйләнә?
14. Әсәрнең теле.
15. Әсәрнең әһәмияте (эстетик кыйммәте, тәрбияви әһәмияте)

# ӘСӘРГӘ ФИЛОЛОГИК АНАЛИЗ ЯСАУ

- I. Гомуми бәяләмә.( 1. Әсәрнең авторы турында мәгълүмат,  авторның шәхси үзенчәлекләре чагылышы, иҗат ителгән чорга, мәдәни-тарихи контекстка бәя һәм аның текстта чагылу рәвеше. Әсәрнең әдәби юнәлеше һәм әдәби иҗат методлары, әсәрнең татар әдәбиятында һәм, гомумән, дөнья әдәбиятында тоткан урыны)
- II. Текстка лингвистик анализ ясау.
- III. Лингвопоэтик анализ.

# ӘСӘРГӘ ФИЛОЛОГИК АНАЛИЗ ЯСАУ

1.Әсәрнең язылу яки басылу тарихы.

2. Образларга характеристика.

3. Символик образлар

4. Сюжет бирелеше. Әсәрнең композициясе. Композицион катламнар

5. Конфликт

6. Әсәрнең темасы

7. Төп фикер (идея)

8. Вакыт-урын бирелеше.

9. Психологизм бирелешен тикшерү.

10. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше

11. Йомгаклау

# РӘМЗИЯ ГАБДЕЛХАКОВАНЫҢ “СИРАТ КҮПЕРЕ” ХИКӘЯСЕ

филологик анализ

# ӘСӘРНЕҢ ЯЗЫЛУ ЯКИ БАСЫЛУ ТАРИХЫ.

Рәмзия Гайсә кызы Габделхакованың хикәяләр, парчалар, нәсерләр тупланган “Көмеш тун” исемле китабы Татарстан китап нәшриятында 2006 елда басылып чыга. Әлеге җыентыкта «Сират күпере» хикәясе дә була. Язучы әйтүенчә, хикәя бер ананың сөйләвенә нигезләнеп языла.

# ПИРАМИДАЛЬ ТАРИХ

1. Вакыйганың төп каһарманы.
2. Каһарманны сыйфатлаучы ике сүз(тышкы кыяфәте, яше, холкы)
3. Вакыйга барган урынны сурәтләүче өч сүз (яшәү урыны, җирлек)
4. Вакыйгадагы проблеманы күрсәтүче дүрт сүз(картлык, ялгызлык, битарафлык һ.б.)
5. Вакыйгада проблемага этәргән сәбәпләрне күрсәтүче биш сүз
6. Проблемалар берничә булса, сүзләр саны арта бара.
7. Проблеманы чишү юлларын сурәтләгән сүзләр.

# РАМИЛ

Әсир, яугир

Кайнар ком, таш-кыялар, упкын

Сугыш, әсирлек, яшисе килү, үлем

Тормыш, битарафлык, имансызлык, сынау

Үкенү, могҗиза, әби сүзләре, иман китерү, исән калу

# ОБРАЗЛАРГА ХАРАКТЕРИСТИКА.

## Рамил – актив герой

Уртача буйлы, төптән таза, каратут йөзле; авылда туып, атеистик тәрбия алып үскән егет, дини тәрбиягә битараф; заманга ияреп, әбисенең сүзләренә игътибар итми, армиягә киткәндә әбисе биреп җибәргән дога кәгазе белән аң җитмәслек кабахәтлек кыла; әфган мәхшәренә эләгә, үлемне түгел, тормышны сайлый, әсирлеккә төшә, әҗәл каршына килеп баскач кына үкенә; Аллаһы Тәгаләне исенә төшерә, иманга килә, алты ел әсирлектә булганнан соң туган җиренә әйләнеп кайта

# ЯРДӘМЧЕ ОБРАЗЛАР

**Әби**- бер уразасын калдырмый, көн саен биш вакыт намазын укый, бисмилласын теленнән төшерми торган чын мөселман әбисе. Оныгы өчен борчыла, иманлы итеп тәрбияләргә тырыша. Армиягә озатканда оныгына дога язып җибәрә.

**Александр Дроздов (Саша)-** Рязань каласында туып үскән, сержант погонлы, калкурак буйлы, сул аягы яралы, ачык зәңгәр күзле, аз сүзле, юмарт күңелле хыялый егет

**Михаил**- эре сөякле, калын муенлы, зәңгәр йөгерек күзле, егермесе дә тулмаган украин егете

**Әфганлы**-баштанаяк коралланган соры киемле, корым кебек кап-кара сакаллы, барысы да бертөсле

# 3. СИМВОЛИК ОБРАЗЛАР

**Караңгы баз-** өметсезлек, котылгысыз күрәчәк символы

**Кояш -** тормыш, үзгәрешләр символы

**Таш- кыялар** - үлем белән яшәүне бәйләүче символ

**Упкын-** үлем, явызлык символы

**Сәгать**-мәңгелек символы

**Юл**-тормыш символы; язмыш күренә торган урын

# СИНКВЕЙН (ФРАНЦУЗ ТЕЛЕННӘН “БИШ” ДИП ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛӘ)-РЕФЛЕКСИЯНЕҢ ИҖАДИ ФОРМАСЫ.

Бирелгән материал һәм мәгълүматны кыска төшенчәләр ярдәмендә синтезлаудан гыйбарәт.

**Синквейн язу кагыйдәләре:**

**Беренче юл-** тема бер сүз аша бирелә (исем сүз төркеме)

**Икенче юл-** ике сүз ярдәмендә билгеләмә бирү(сыйфатлар)

**Өченче юл-** эш,хәрәкәт,хәлне тема кысаларында өч сүз белән сурәтләү (фигыльләр)

**Дүртенче юл-** темага караган дүрт сүзле фраза(хис бер фраза белән белдерелә)

**Бишенче юл-** теманы кабатлый, аның синонимы бер генә сүздән тора

# РАМИЛ

битараф, кызганыч

Сугыша, әсир төшә,кайта

Ашыгып, тиз баручы кеше

Әсир солдат

# 4. СЮЖЕТ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

**экспозиция-** (Әфган сугышына эләккән Рамил, каты бәрелештән соң, исән калган алты иптәше белән мөҗәһитләр кулына әсир төшә. Сугышып һәлак булуга караганда, алар әсирлекне сайлыйлар. Чөнки әсирлек ул- барыбер тормыш).

**төенләнеш-** (аларга упкын аша сузылган бүрәнә (“сират күпере”) аша үтү өчен иман китерергә кушалар).

**хәрәкәт үстерелеше-** ( бер-бер артлы Саша, Михаил “сират күпере”н кичә алмыйча һәлак булалар).

**кульминация**- (Чират Рамилгә җитә. Аңа да иман китерергә кушалар).

**чишелеш**- (Рамил куркыныч алдында әбисенең һәр сүзен, теләк-догаларын искә төшерә Аның белән бергә дүрт урыс малае да исән кала.).

**эпилог-** (Алты ел әсирлектән соң, туган җиренә әйләнеп кайткан Рамил әбисенең кабер ташы белән очраша. Анда иман китергән көн чокып язылган була).


# ФИШБОН-

турыдан- туры “балык сөяге” дип тәрҗемә ителә.

Бу стратегия тулаем проблеманы төрле өлешләргә һәм аргументларга бүлергә ярдәм итә.

# СЮЖЕТ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

- **Экспозиция  төенләнеш  хәрәкәт үстерелеше  кульминация чишелеш**



**?  ?  ?  ?  ?**

# 5. КОНФЛИКТ.

Әхлакый планда каршылык әбисенең теләк-догалары һәм аларга битараф Рамил арасында туа

# 6. ӘСӘРНЕҢ ТЕМАСЫ

Иманга тугрылык

Яшәү мәгънәсе

# 7. ТӨП ФИКЕР (ИДЕЯ)

Теләсә нинди шартларда да Кеше иманын җуймаска һәм кешелек дәрәҗәсен югалтмаска тиеш

# 8. ВАКЫТ-УРЫН БИРЕЛЕШЕ.

Вакыйгалар әфган җирендә башланып китә, таш-кыялар янындагы упкын читендә дәвам итә һәм соңыннан әбисенең кабер ташы каршында тәмамлана.

**Хикәядә ике вакыт сызыгы кисешә:**

сугышта әсир төшеп, үлем белән яшәү арасында бәргәләнгән егет үткәндәге хәтирәләрне барлый.

# 9. ПСИХОЛОГИЗМ БИРЕЛЕШЕН ТИКШЕРҮ.

**Хикәядә:** *кеше күңеле, анда кайнаган хис-тойгылар сурәтләнә.*

**Укучы:** *борчыла, сөенә, нәфрәтләнә, кызгана куана.*

# ӘСӘРНЕҢ СӘНГАТЬЧӘ ЭШЛӘНЕШЕ

**ПАРЛЫ СИНОНИМНАР:** МАЛАЙ-ЕГЕТ, АШАТМЫЙ-ЭЧЕРТМИ, ТАУ-КЫЯЛАР, БАШЫ-КҮЗЕ,КУРЫКМЫЙ-ШИКЛӘНМИ һ.Б.

**ЧАГЫШТЫРУЛАР**: КӨЗГЕ КЕБЕК ЯЛТЫРАП ТОРА, ТАШТАЙ САЛКЫН ЙӨЗ, МУНЧА ТАШЫДАЙ КЫЗГАН һАВА,, БОЗДАЙ САЛКЫН КУЛЛАР һ.Б.

**МЕТАФОРАЛАР**: БОРЧАК МИҢ һ.Б.

**СЫНЛАНДЫРУ**: ТАУЛАР ЫҢГЫРАША һ.Б.

**ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР**: ХӘБӘР ҖИТКЕРҮ, КОТ ОЧУ, АКЫЛ КЕРМӘҮ, ТЫН ДА АЛМЫЙ КҮЗӘТҮ, ҮТӘЛИ ТИШЕП КАРАУ һ.Б.

**ЭПИТЕТЛАР:** АЧЫК ЗӘҢГӘР КҮЗЛЕ, ЭРЕ СӨЯКЛЕ, КӨЧЛЕ ТАВЫШ, КИПКӘН ИРЕННӘР, УТ КАРАШЛЫ КЕШЕ, ЙОМШАК БАСУ, НУРЛЫ ЙӨЗ, ТОМАНЛЫ КҮЗЛӘР ТӨПСЕЗ КҮК, ЯЛКАУ ҖИЛ, БӘРГӘЛӘНГӘН ӨМЕТ, РӘХИМСЕЗ КОЯШ һ.Б

**РИТОРИК СОРАУ һӘМ РИТОРИК ЭНДӘШ**: НИК СОҢ ИСКӘ ТӨШМ, НИК СОҢ ИМАН КИТЕРҮНЕҢ НИ ИКӘНЕН АҢЛАМЫЙ РАМИЛ?! КЕМ ЧИРАТЫ? ПАЛАЧНЫҢ КЫСКА ЮАН БАРМАГЫ КЕМ КҮКРӘГЕНӘ КИЛЕП КАДАЛЫР?

# ӘСӘРГӘ ЛИНГВИСТИК АНАЛИЗ ЯСАУ

1 . Го м у м и к ү з ә т ү , т а р и х и - м ә д ә н и э к с к у р с ясау (әсәр язылган чорга, шул елларда татар мәдәниятенә хас сыйфатларны барлау, тарихи үзенчәлекләрне билгеләү)

2. Абзацара бәйләнеш (фикер күчеше ярдәмендә бирелә,фараз, фаразның дөреслеген җөпләү һ.б.)

3. Текстның лексик составы (сүзләрнең килеп чыгышы, этимологиясе, ономастик элементлар,синонимнар, антонимнар, фразеологизмнарның кулланылышы)

4. Сурәтләү чаралары (эпитет, метафора, чагыштыру)

5. Морфологик үзенчәлекләр (сүз төркемнәре, кушымчалар кулланылышы)

6. Синтаксик үзенчәлекләр (гади, кушма җөмләләр, аралашу формалары)

7. Пунктуацион үзенчәлекләр (тыныш билгеләренең кулланылышы)

8. Текстның хисси-халәт кыры (өндәү җөмләләрнең, риторик сорауларның бирелеше)

9. Текст белән эшләүгә йомгак ясау

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!